**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.05.2024 № ПР-82

**«2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны, шул исәптән социаль эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы законы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны, шул исәптән социаль эшкуарлыкны үстерү» кушымтада бирелгән программаны расларга.
2. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны, шул исәптән социаль эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 08 апрелендәге ПР-62 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Программаны башкаручыларга Программа чараларын вакытында һәм тулысынча үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов